| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ГЛАВА НОВОИГАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА ИГЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Яңа Иглай ав. **КАРАР**

«01» ноябрь 2025 ел № 4

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Иске Иглай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ**:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Иске Иглай торак пунктында гыйбадәт йорты янында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 20 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

3.1. «2026 елда Яңа Иглай авыл җирлегенең Иске Иглай авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, СВОда катнашучылардан тыш, 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- урамнарны яктырту җайланмасы (товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Иглай авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу)».

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Яңа Иглай авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы М.И. Хәмидуллин